НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО



# УРМАН КЫЗЫ

(ПОЭМА)

**Сафиулла ӘҺЛИУЛЛИН**
**Иске Мөъмин авылы,**
**Әсәкәй районы.**

**Дәвамы. Башы 6-8 нче саннарда.**

## Алтынчы бүлек

Олеся кайтып
Торгач аз гына,
Торып йөгерде
Иптәш кызына.
Иптәше тора
Авыл очында.
Егете килә
Еш кына шунда.
Бүген дә егет
Килгән ашыгып,
Кызыйны көтә
Урамга чыгып.
Төсе үзгәргән,
Кайгыга калган.
Сугыш башланган,
Түгел ди, ялган.
Аерылышмаска дип,
Сүз бирештеләр.
Бергә утырып
Чәй дә эчтеләр.
Аннары егет
Китте өенә.
Көннәр дә үтте
Бер көйгә генә.
Бер айлардан соң
Егет югалды.
Мескен Олеся
Берьялгызы калды.
Әтисе дә
Югалып тора.
Нишләргә белми,
Планнар кора.
Ничә мәртәбә
Эзләп килделәр,
Кайтса хәбәр ит
Безгә диделәр.
Бервакыт шулай
Полицай керде.
Теләгең булса
Бар эшкә диде.
Җыештыручы булып
Комендатурага.
Кеше чакыра,
Мичкә дә яга.
Кыз риза булып
Тотынды эшкә.
Өенә кайта
Гел калып кичкә.
Өйдә мал да бар,
Авыр кызыйга.
Кайчак ялына
Күрше абзыйга...
Көн артыннан көн
Сизелми үтә.
Кызый өзелеп
Егетен көтә.
Бер төнне шулай
Тәрәзә чирттеләр.
Тавышны сизеп
Этләр өрделәр.
Кызый тәрәзәдән
Тышка күз салды.
Караңгыланды
Аның күз алды.
Егете килгән
Иске киемнән.
Хәбәре дә бар
Белсәгез кемнән.
Әтисе аңа
Сәлам җибәргән.
Кызым үзеңне
Саклый күр дигән.
Егет ныгытып
Кызны кисәтте.
Партизан булып
Йөргәнен әйтте.
Әтисе дә
Алар янында,
Кайтып китә алмый
Гел йөри юлда.
Полицайлар да
Моны белгәннәр.
Кем тота шуңа
Бүләк дигәннәр.
Җәй үтеп бара.
Көз якынлаша.
Кыз да йокламый,
Төнлә саташа.
Әтисе дә гел
Уенда аның.
Бер күрер өчен
Кызганмас җанын.
Көн буе эштә,
Кичен берүзе.
Ашау да качты
Саргайды йөзе.
Немецлар мактый,
Эшендә яхшы.
Яшертен генә
Куйдылар сакчы.

**(Дәвамы киләсе санда)**

ИСЛАМ

# ЯХШЫ СҮЗ

**Дәвамы. Башы 8нче санда.**

Нәрсә турында күбрәк сөйлибез, берәр кешенең игътибар итеп караганы бармы? Авылда да, шәһәрдә дә бик матур яши торган гаиләләр бар. Үзебездә дә аракысыз туйлар ясап өйләнешеп, биш вакыт намазны калдырмыйча, аракы кулланмыйча, балалар үстерүче, хөкүмәт эшендә дә эшләүчеләребез арта бара, әлхәм-дүлилләһ. Әмма без аларны күрмибез, алар турында сөйләмибез, язмыйбыз. Авылда яки шәһәрдә берәр гаиләдә ызгыш-талаш чыкса, кемдер үтерешсә, аны халык сөйли, бөтен газит яза. Килен белән каенана да гел әрләшеп кенә яшәмиләр, бер-берсенә күп кенә игелекләр дә эшлиләр, күркәм сүзләр дә әйтәләр, әмма бу турыда берсе дә урамга чыгып сөйләми. Ходайның бер бирмеш көнендә ниндидер аңлашмаучылык чыкса, берәр ярамаган сүз ычкынса, менә монысын бөтен кеше белә. Нәрсә дип әйткән, ничек әйткән, берсе дә калмый, урамда сөйләнә.

Бер кеше җитәкчегә барып нәрсәдер сораса, җитәкче аның үтенечен канәгатьләндерсә, берәү дә бу хакта башкаларга әйтми. Ә инде кире борып чыгарса, ул җитәкченең кем икәнен, атаанасының кем икәнен, нәрсәне бирмәгәнен урамда очраган бар кешегә дә диярлек җиткерелә.

Сау-сәламәт килеш йокыдан уянсак, сөенеп, әлхәмдүлилләһ, дип бик сирәк әйтәбез, яки бөтенләй әйтмибез. Әлбәттә инде, беркемгә дә: «Бүген бер җирем дә авыртмый әле», -дип мактанмыйбыз. Әгәр инде берәр җиребез авыртып уянсак, өйдәгеләрдән башлап, кичкә кадәр ничә кеше очраса, барысына да кай җиребез бимазалый, ничегрәк авырта, түкми-чәчми җиткерәбез.

Күрше малае күчтәнәч итеп нәрсәдер алып керсә, аны без берәүгә дә белдермибез. Әгәр инде шул күрше малае нәрсәнедер эләктереп, урлап китсә, монысын бар кеше дә белә.

Ир кеше хатынына акча алып кайтып бирсә, аның күпме акча алып кайтканын берәү дә белми. Бу бер хәрби сер шикелле. Әгәр дә инде эчеп-туздырып бетерсә, иренең ничә сумлык аракы эчкәнен бөтен авыл белә.

Менә болар барысы да безнең кальбләрнең кара икәнен, дөрес яшәмәвебезне күрсәтә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.): «Аллаһ гүзәл, гүзәллекне сөя», — ди. Тормышта бит, әлхәмдүлилләһ, бик күп гүзәл вакыйгалар да булып тора, тирәбездә яхшы кешеләр дә җитәрлек. Өйдәгез, әнә шул матурлыкны күрә, бәяли белик, гүзәл үрнәкләр, гүзәл холыклар, күркәм кешеләр турында күбрәк сөйлик, күбрәк язык. Җир йөзендә гүзәллекне таратучылардан булырбыз.

Яхшы сүзләрнең дә иң әфзалы, иң күркәме: «Ләәә илләәһә илләлаааһ, Мухәммәдүр Расүүлуллааһ». Без һәркайсыбыз бу кәлимәне белергә, мәгънәсенә төшенергә, Аллаһны чын тану белән таныргa тиеш булабыз. Шуны аңлый, шуңа төшенә алган кеше бәхетле була, гыйбадәтләрен җиңеллек белән үти, кальбен чистарта һәм инде андый күңелләрдә яман сүзләргә, яман фигыльләргә урын калмый.

Аллаһ Раббыбыз барчабызны да иман белән дөньяга китерде, шушы иманнарыбызга тугры калган хәлдә, Аллаһ риза булырлык итеп дөньяда яшәргә, иман белән дөньядан үтеп, Аллаһның мәңгелек сәгадәтенә дә ирешергә насыйп булса иде.

**Илдар БАГАУТДИНОВ.**
**Әсәкәй авылы.**

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ



(время местное, летнее)

| ИЮНЬ | Фаджр Иртә | Восход Кояш чыга | Зухр Ойлә | Аср Икенде | Магриб Ахшам | Иша Ясту |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 5-07 | 6-07 | 15-10 | 20-54 | 22-54 | 24-24 |
| 2 | 5-06 | 6-06 | 15-10 | 20-55 | 22-55 | 24-25 |
| 3 | 5-05 | 6-05 | 15-10 | 20-56 | 22-56 | 24-26 |
| 4 | 5-05 | 6-05 | 15-10 | 20-57 | 22-57 | 24-27 |
| 5 | 5-04 | 6-04 | 15-10 | 20-58 | 22-58 | 24-28 |
| 6 | 5-04 | 6-04 | 15-10 | 20-59 | 22-59 | 24-29 |
| 7 | 5-03 | 6-03 | 15-10 | 21-00 | 23-00 | 24-30 |
| 8 | 5-02 | 6-02 | 15-10 | 21-01 | 23-01 | 24-31 |
| 9 | 5-01 | 6-01 | 15-10 | 21-02 | 23-02 | 24-32 |
| 10 | 5-01 | 6-01 | 15-10 | 21-03 | 23-03 | 24-33 |
| 11 | 5-01 | 6-01 | 15-10 | 21-04 | 23-04 | 24-34 |
| 12 | 5-00 | 6-00 | 15-10 | 21-05 | 23-05 | 24-35 |
| 13 | 5-00 | 6-00 | 15-10 | 21-05 | 23-05 | 24-35 |
| 14 | 5-00 | 6-00 | 15-10 | 21-06 | 23-06 | 24-36 |
| 15 | 4-59 | 5-59 | 15-10 | 21-06 | 23-06 | 24-36 |
| 16 | 4-59 | 5-59 | 15-10 | 21-06 | 23-06 | 24-36 |
| 17 | 4-59 | 5-59 | 15-10 | 21-07 | 23-07 | 24-37 |
| 18 | 4-59 | 5-59 | 15-10 | 21-07 | 23-07 | 24-37 |
| 19 | 4-59 | 5-59 | 15-10 | 21-07 | 23-07 | 24-37 |
| 20 | 4-59 | 5-59 | 15-10 | 21-08 | 23-08 | 24-38 |
| 21 | 4-59 | 5-59 | 15-10 | 21-08 | 23-08 | 24-38 |
| 22 | 4-59 | 5-59 | 15-10 | 21-08 | 23-08 | 24-38 |
| 23 | 5-00 | 6-00 | 15-10 | 21-08 | 23-08 | 24-38 |
| 24 | 5-00 | 6-00 | 15-10 | 21-08 | 23-08 | 24-38 |
| 25 | 5-00 | 6-00 | 15-10 | 21-09 | 23-09 | 24-39 |
| 26 | 5-01 | 6-01 | 15-10 | 21-09 | 23-09 | 24-39 |
| 27 | 5-02 | 6-02 | 15-10 | 21-09 | 23-09 | 24-39 |
| 28 | 5-03 | 6-03 | 15-10 | 21-09 | 23-09 | 24-39 |
| 29 | 5-03 | 6-03 | 15-10 | 21-09 | 23-09 | 24-39 |
| 30 | 5-03 | 6-03 | 15-10 | 21-09 | 23-09 | 24-39 |

**Данные предоставлены Бугурусланской мечетью. Возможна разница во времени в сравнении с другими источниками, на 3-5 минут.**